**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2024 елның, 11 ноябре** **№ 15**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 28 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Люгдон авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Люгдон авылы, Лесная ур., 3 йорт адресы буенча үткәрергә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «сез 2025 елда Кукмара муниципаль районы Түбән Рус авыл җирлегенең Люгдон бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау; (энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, килешү буенча түләү); электр җиһазлары һәм комплектлаучы элементлар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (җәйге вакытта юлларны кардан чистарту һәм территорияләрне чабу; дизель ягулыгы сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Сәфәров

СОВЕТ НИЖНЕРУССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ҮРӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607753133
ИНН 1623002015